# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Мәмдәл авыл җирлегенең Мәмдәл ав. торак пунтында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

06 декабрь, 2021 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торак пункт территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегенең Мәмдәл ав. торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ яшьтәге кешедән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне:

а) тирәнлек насосын сатып алу.

б) юлларны карап тоту.

в) материал сатып алу һәм зиратны киртәләү.

г) колонкаларны һәм су кудыру линияләрен ремонтлау өчен материаллар сатып алу.

д) урам яктырту челтәрләрен ремонлау һәм карап тоту.

үтәү буенча юллау белән килешәсезме?»

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

дигән сорау буенча 2021 елның 02 декабрендә 14.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 400 (дүрт йөз) граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 201 кеше, бу 50 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында 201 (ике йөз бер) катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 (ноль) катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мәмдәл авыл җирлеге Мәмдәл ав. торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авылы җирлеге Мәмдәл ав. торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йөз) суммада үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) тирәнлек насосын сатып алу.

б) юлларны карап тоту.

в) материал сатып алу һәм зиратны киртәләү.

г) колонкаларны һәм су кудыру линияләрен ремонтлау өчен материаллар сатып алу.

д) урам яктырту челтәрләрен ремонлау һәм карап тоту.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Ф.Г.Сафиуллин